ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39. E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге генераль планы проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2013 ел № 131-ФЗ Федераль законына таянып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы халкының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу хокукын гамәлгә ашыру максатларында, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында»23.12.2023 ел, № 131-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Югары Ослан муниципаль районы Советының 2020 елның 04 июнендәге 58-670 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә белән.

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлегенең генераль планы проектын карау буенча иҗтимагый фикер алышулар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән проектны карау буенча җәмәгать фикер алышуларын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген (алга таба - җәмәгать фикер алышуларын оештыручы) билгеләргә.

3. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы – коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе А. А. Әхмәтшин;
- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. Д. Сәгъдиева;
-Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру-хокукый һәм кадрлар эше җитәкчесе Н.В. Пичугина;
- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Югары Ослан авыл җирлеге җитәкчесе Т. М. Дәүләтшин;

4. Җәмәгать фикер алышуларын оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә җәмәгать фикер алышуларын оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

5. Иҗтимагый фикер алышулар үткәрү чорын 2026 елның 3 февраленнән 2026 елның 4 мартына кадәр билгеләргә.

6. Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручыга Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 ст. нигезендә иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр әзерләргә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының (https://verhniy-uslon.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

8. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль район районы
Башлыгы вазифаларын башкаручы С.В.Осянин